15 декабрь, 2017 ел № 21/14

Яр Чаллы шәһәре халык депутатлары Советының 2005 елның 17 мартындагы 31/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре гербы һәм флагы турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 5, 28 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре халык депутатлары Советының 2005 елның 17 мартындагы 31/5 санлы Карары белән расланган Яр чаллы шәһәре гербы һәм флагы турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.3.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Яр Чаллы шәһәре гербы түбәндәге бланкларда урнаштырыла:

– Шәһәр Советы Карарлары, Яр Чаллы шәһәре Хакиме карарларында, боерыкларында;

– Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитет Җитәкчесе карарлары, боерыклары;

– Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитет район Администрацияләре башлыклары һәм җирле үзидарәнең башка вазифаи затларының боерыкларында;

– Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары, Яр Чаллы шәһәре Башкарма Комитет территориаль һәм тармак (функциональ) органнары бланкларында;

– муниципаль милектәге предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләре бланкларында;

–җирле үзидарәнең, муниципаль милектәге предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләрнең рәсми басмаларында.»;

2) 2.3.3. пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре гербы Шәһәр Советы депутатлары һәм аларның ярдәмчеләре, җирле үзидарә органнарының муниципаль вазифаларын биләүче затлар, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль милектәге предприятие, оешма, учреждение хезмәткәрләре таныклыгында сурәтләнә.»

3) түбәндәге эчтәлектәге 2.3.8 пунктын өстәргә:

«2.3.8. Яр Чаллы шәһәре гербын куллануның башка очраклары Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының хокукый акты белән расланган тәртиптә билгеләнә.»;

4) 3.3.7. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.7. Яр Чаллы шәһәре флагы муниципаль милектәге транспорт чараларында урнаштырылырга мөмкин.»;

5) 4.4. пунктында «администрация» сүзен «Башкарма комитет» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ